КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 2 март г.Казань № 6-333

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 59 статьясындагы 13 өлеше нигезендә урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштергән белем алучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

2026 елда бердәм дәүләт имтиханын, дәүләт чыгарылыш имтиханын үткәрүне тәэмин итәргә;

2026 елда «Туган тел (татар теле)» һәм «Туган әдәбият (татар әдәбияты)» предметларын өйрәнгән һәм әлеге предметлардан имтихан бирүне сайлап алган белем алучылар өчен туган тел (татар теле) һәм туган әдәбият (татар әдәбияты) буенча бердәм республика имтиханын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына имтиханнар үткәрү пунктларында медицина персоналының кизү торуын оештыруда ярдәм күрсәтергә.

3. Бердәм дәүләт имтиханын, дәүләт чыгарылыш имтиханын һәм туган тел (татар теле) һәм туган әдәбият (татар әдәбияты) буенча бердәм республика имтиханын үткәрү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары белән берлектә, имтиханнар үткәрү пунктлары янындагы территорияләрдә иҗтимагый тәртипне саклауда һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә кирәкле ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин